СОВЕТ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

14.05.2020 с. Сарманово № 236

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «Сарман муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» 2019 елның 7 октябрендәге 194 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясе Бюджет кодексының аерым нигезләмәләрнең гамәлдә булуын туктатып тору һәм 2020 елда Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары үтәлеше үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 22 апрелендәге 120-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Сарман муниципаль районы Советы карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Советының «Сарман муниципаль районында бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында» 2009 елның 7 октябрендәге 194 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 30 статьяның 2 пунктында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2) 35 статьяның 4 пунктында «һәм үтәлә» сүзләрен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Сарман муниципаль районының Интернет-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль район Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Сарман муниципаль районы
Советы Рәисе Ф.М.Хөснуллин

Совет Сармановского муниципального района
Сарман муниципаль районы Советы